
Рафаил
Газизов
Җиләкле алан

Рафаил
Газизов

Җиләкле алан

ШИГЫРЬЛӘР

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1988

ББК 84(2Р-Тат)-5
Г16

Художнигы В. БУЛАТОВ

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Газизов Р. Ш.

Г16 Җиләкле алан: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.— 32 б.

Г $\frac{4803010200-234}{М132(03)-88}$ 178—88

ББК84(2Р-Тат)-5

© Татарстан китап нәшрияты, 1988

ҖИЛӘККӘ БАРГАН ИДЕК

Бурсык елгасында җиләк
Кызарып пешкән, диләр.
Олы чыпчык башы кадәр,
Валлаһи, үскән, диләр.
Шаккаттырыйк әниләрне
Җиләк апкайтып биреп,
Сөенсен әле әбиләр
Безнең үскәнне күреп.
Киңәшкә җыйдым Фаилне,
Раилне, Гөлнараны,
Марат, син күп сөйләшәсең,
Кешегә әйтмә, кара аны!
Сүз башладым:
— Бу тирән сер.
Абыйлар белмәсеннәр,
Шундый шәп җиләклек таптым,
Сизенә күрмәсеннәр.
Иртән, кояш чыгар-чыкмас,
Олы савытлар алып,
Шул савытларның төбенә
Бераз ашарга салып,

Бакча артлап, мыштым гына,
Төрлебез төрле яктан:
Мин — бәрәңге ызаныннан,
Марат, син шушы чаттан,
Гөлнара Барый абыйның
Киртәсе кырыеннан,
Ә Фаил белән Раил
Көтүчеләр юлыннан
Салкын чишмә тугаена
Иртүк төшеп җитик без,
Җыелышып бетик без
Һәм җиләккә китик без.
Тагын әйтәм: нинди савыт
Алу, дуслар, сезнең эш,
Тик ул савыт буш арбадай
Шалтырамаска тиеш.
Алайса сизенерләр,
Планнар өзелерләр,
Хәзер өйләргә кайтыйк,
Шундук йокларга ятыйк!

Өч торып карадым төнлә
Өстәлдәге сәгатьне,
Шикләнәм, юкмы икән дим
Артта калу гадәте.
Йокламадым, мин — командир,
Кичегергә ярамый.
Минем әти белеп әйтә:
Вәгъдә яшькә карамый!
Яктыра гына башлады,
Аяк очына басып,
Өйнең кичтән генә майлап
Куйган ишеген ачып,
Ишегалдына элдердем

Алып киемнәремне.
Тырысны кидем беләккә,
Ызанда тезләремне
Әй яндырды кычытканнар,
Борылып карамадым,
Чик сакчысы кебек үттем
Бәрәңге араларын.
Мин чишмә янына төшсәм,
Хәлләр бар икән монда:
Марат йоклый, төренгән дә
Бабасының тунына.
Башы эшләгән малайның!
— Марат дус, тор, юыныйк,
Таң суы ага чишмәдән,
Тамчыларда коеныйк!
Качты йокы. Чишмә суы
Көйдереп алды тәнне.
Санамадык, җылыныйк дип,
Ничә кат сикергәнне.
Без әзер, шулай да, дуслар,
Тамаша алда икән:
Нәни Фаил үзе кадәр
Чемодан алып төшкән.
Раил иләк эләктергән —
Җиләк илисе бардыр,
Тилертәләр болар мине,
Уф, йөрәгем, бул сабыр.
Барлап чыктым. Миндә — тырыс,
Раил башында — иләк,
Фаил чемодан күтәргән,
Марат, Гөлнара — чиләк.
Тау мендек. Сукмак борылды
Арышлар арасына,
Атлыйбыз нурлы кояшның
Нәкъ үзе тарафына.

Алдыбызда арышларны
Янгын чорнаган кебек,
Тезелешеп ут диңгезе
Эченә киттек кереп.
Пешкәннәр дип борчылмагыз.
Арышлар арасына
Кояш утлы толымнарын
Таратып салган гына.
Мин, Фаилнең чемоданы
Эченә иләк салып,
Ухылдап күтәреп барам
Бер келеп, бер офтанып.
Арыды юеш борыннар,
Ялга план коралар,
Ни әйтсәң дә сөйләшүне
Гел ашауга боралар.

Туктадык ике сукмакның
Кисешкән урынына.
Җилкәдән төште чемодан —
Ул безнең өстәл була.
Уртак табынга куелды
Төш, майлы ипи, дучмак,
Җиде кыяр, алты коймак,
Бер кыстыбый, өчпочмак.
Сыйландык. Кәефләр әйбәт —
Уйнадык бер туйганчы,
Теге иләк яньчелгәнче,
Чемодан сытылганчы.
Искә төште: бит Бурсыкта
Җиләкләр пешкәннәрдер,
Инде бүтән савытларга
Өзелеп төшкәннәрдер.
Кузгалдык, әй йөгерәбез,

Җиттек бер тау башына —
Нинди хәл бу? Безнең авыл
Көлеп ята каршыда.
Харап итте шул кыярлар,
Харап итте өчпочмак,
Харап итте шул дучмаклар,
Адаштырды шул сукмак!
Ә хәзергә мыштым гына
Төрлебез төрле яктан:
Мин — бәрәңге ызанынынан,
Марат, син шушы чаттан,
Гөлнара Барый абыйның
Киртәсе кырыеннан,
Ә Фаил белән Раил
Көтүчеләр юлыннан —
Сыпыртабыз өйләргә, тик
Кеше-кара күрмәсен,
Күрше-күлән белмәсен,
Бармак төртеп көлмәсен.

Өйдә, эшче кайтты диеп,
Әни чәй белән сыйлый,
Табында — бер табак җиләк,
Никтер алырга кыймыйм.
Ул җиләге! Валлаһи,— дим,—
Олы чыпчык башыннан!
Әни Бурсыкка бармаган,
Җыйган ындыр артыннан.

БЕЗНЕҢ УРАМ

Урамыбыз — гөл урамы.
Килегез, ышанмый кемнәр?!
Аяк очларына басып
Рәшәткәдән карый гөлләр.

Ул гөлләрдән дә үрелеп
Әле мин карап торам.
Бер җирдә юк шундый матур
Йортлары булган урам.

Ә шулай да иң сөйкемле,
Күп сөмбелле һәм сиреньле
Гаҗәеп өй бар урамда —
Әйтче, кемнәр яши анда?

Гөлгә чумган өй хакында
Нәрсә генә әйтсәм дә аз.
Сиңа гына чишәм серне:
Яши анда
Гөлназ,
Гөлназ!

КӨННЕ ҮЗЕМ ҖЫЛЫТАМ

— Мәче идәнгә ятып
Йокласа,— ди әбием,—
Көннәр җылынуга була,
Бел син шуны, бәбием.

Көн суык, әгәр җылынса,
Урамга чыгар идем.
Әрәм тора ясаган тау,
Чанада шуар идем.
Мәчене ничә мәртәбә,
Вак мендәрләргә төреп,
Идәнгә йокларга салдым.
Кача шул мичкә кереп.



Киендем дә көрәк алып
Чыгып киттем урамга,
Җил ничек ташып өлгергән —
Кар тутырган юлларга.
Бу сукмактан әниемнең
Фермага йөрисе бар,
Бу юлдан бакчага барам —
Аны да күрисе бар.
Ә бу юлдан күрше бабай
Дәваланырга йөри.
Тирләп беттем күршеләрнең
Сукмагын көри-көри.
Бар да миңа рәхмәт укый,
Йөриләр чиста юлдан.
Эшләсәң көн җылы икән,
Инде хәзер тау шуарга
Мәчене алып чыгам.

КҮРШЕБЕЗГӘ БЕР КЫЗ КИЛГӘН

Күршебезгә бер кыз килгән,
Суга төшкәндә күрдем.
Дәштем аңа сайлый-сайлый
Матурын гына сүзнең.

Сөйләшеп кайтабыз судан
Күргән-белгән турында,
Су бушаткач очрашабыз
Тагын чишмә юлында.

Су сиптем алмагачларга,
Җиләк, чия, гөлләргә;
Үрдәкләр йөзеп йөриләр
Мин ясаган күлләрдә.

Әни мактый, әби мактый,
Бабай да тел шартлатты,
Әти эштән кайтып керде,
Эшне күрде — шаккатты.

Көннәр үтте, сулар бетте.
Бакчада — тузан уйный.
Әни әйтә: — Кунак кызын
Тагын чакырмый булмый...

##ҺИЧ ТӘ УЙЛАМАГАНДА

Безнең урам шулкадәр киң,
Ун машина тезелсә дә,
Яңгыр яугач гөрләвекләр
Агып төшеп бөялсә дә,
Барысын да сыйдыра ул.
Тик сыялмыйбыз без генә,
Мин һәм күрше Илгиз генә.
Үтә гомер урам булеп
Һәм чикләрне бозып кереп,
Урамыбыз таррак шул...

Талашканны беркөнне
Нургали абый күрде:
— Яшь этәчләр,— дип көлде.
Аннан: — Егетләр,— диде,—
Басуга барасызмы,
Я монда каласызмы?

Сизми калдык, бертавыштан:
— Барабыз! — дип кычкырдык.
Машина кабинасына
Очып менеп утырдык.

Комбайннан өчәүләшеп
Икмәк ташыдык, малай,
Урамдагы тавыкларны
Пырлап качырдык, малай.

Ул басуда, басуда
Машина да машина!
Әле сыйлап кайтардылар —
Тәмле, ай-яй, ашы да!

Чик бүлеп аптырый идек
Илгиз белән урамда;
Һич тә уйламаганда,
Сыйдык бер кабинага...

ЯЛ КӨНЕНДӘ

Ачык дәрес бирә бүген дөнья,
Чишмәләре дәшә безне дә.
Бака шигырь сөйли, туган җирне
Олылау бар һәрбер сүзендә.

Ә инештә йөзү бәйгеләре,
Маймычлары гаҗәп терeләр,
Кояш нуры коена дулкыннарда,
Ялтырыйлар балык-көзгеләр.

Үлән арасында минем белән
Качыш-качыш уйный чикерткә,
Җәй гөлләре чикерткәләр итеп
Шаянлыгын чөя ич күккә.

Янәшәдә урман. Агачлары
Инша яза шундый бирелеп,
Күләгә-шәл җиргә төшә шуып,
Тик бирәү дә алмый үрелеп.

Ачык дәрес бирә бүген дөнья...
Чишмә чыңы күккә үрелә.
Туган җирем,
Мең төсләре белән
Җәйгор * булып җанга чигелә.

---

* Җәйгор — салават күпере.

САЕСКАН КУНСА...

«Очып йөреп, өй тирәңә
Саескан кунса килеп —
Озакламас, кунак килер,
Тор, улым, шуны белеп».

Әбисе нәни Наилгә
Беркөнне шулай дигән,
Көннәр үткән, малай көткән,
Саескан очып килгән.

Наил көнозын көтсә дә
Никтер кунак килмәгән,
Чәчәк аткан алмагачны
Ул кунак дип белмәгән.

ХӘЛНЕ ӘНИ КҮРӘСЕ БАР

Кар өсте — яп-якты калай,
Уйнап йөри кояш-малай,
Өйдән чыктым яңа гына,
Мендәр сыры яңагымда.

Кояш-малай белән уйнап
Чабып киттем урам буйлап,
Һәр гөрләвек шаулап ага,
Итегеңә кертми кара!

Киемнәрем лыч су булды,
Бабай әйтә: — Көн сындырды.
Минем тырышканны белми,
Җиңнән су тамганны күрми.

Хәлне әни күрәсе бар...

КЕМ УЛ?

Әни — таңда уятучы,
Әти — каеш уйнатучы,
Абый — кыйнап елатучы,
Апа — сыйпап юатучы.

Әби — әкият иле,
Бабаем — юкә балы,
Әнем — өзми-куймый елап
Болгатучы дөньяны.

Ә кемне күрүгә мәче
Диван астына сыза
Һәм урамның барлык эте
Өреп чыга каршыга?

Кем бакчабызда кошларның
Котын алган таш атып?
Кем икән ул? Вәт — табышмак,
Я, карагыз баш ватып.

БЕЗНЕҢ ӨЙДӘ ИКЕ ӘТӘЧ

Берсе — тавык генералы,
Яши ул кетәклектә.
Талый казны, сарыкларны,
Этне уза этлектә.

Ишегалды тулысынча
Аның биләмәсендә.
Мәчебезнең коты чыга
Күрсә күләгәсен дә.

Икенчесе — үзем булам.
Сугышып кайтып кергәч:
«Әтәч кайтты!» — дип кычкыра
Сеңелем, мине күргәч.

Урамдагы малайларны
Җиңеп була анысы,
Тик үзебезнең әтәчне
Ни эшләтеп карыйсы?

Энем белән икәүләшеп
Бүген уйлап карарбыз.
Киңәшле эш таркалмый ул,
Бер-бер җаен табарбыз.

ИНЕШ

Хәзер яз. Таныш инешкәй
Салганмы кар юрганын?
Төш янына — һәм тоярсың
Сине бик сагынганын.

Сөйләшер ул якын итеп,
Дусларча, челтер-челтер,
Балыклары да сәламләп
Канатын җилпеп китер.

Ул, кабат бер дә йокламый,
Сине көтеп торачак,
Шушы көннән инешкәең
Гомерлек дус булачак.

Тик чишмәне чистартырга
Көрәкне аласың бар,
Болын тугайларына
Таң сукмагы саласың бар.

ИКЕ КӨННЕҢ БЕРЕНДӘ

Ике көннең берендә —
Менә әле бүген дә
Әти шәһәргә бара
Җыелышка-мазарга.

Ә сеңелем белән без
Аны сагынып көтәбез.
Дүрт күзебез дә юлда,
Тизрәк кайтса ни була?

Менә капка ачылыр,
Сагынулар басылыр,
Әтием кайтып керер —
Кем аны алдан күрер?!

Мин алдан күрсәм икән,
Күккә сикерсәм икән.
Сумка булыр кулында,
Безнең күз шунда гына...

Күчтәнәчләр ашый сеңелем
Әтинең муенында,
Мине «карт чыпчык» диләр шул,
Мин бары — куенында...

ӘНЕМ ҮСӘ

Нәрсә генә булды икән?!
Әти кызган, әти кызган! —
Әнем күзлек савытыннан
Ике көймә ясап куйган.

Тишеп мачталар утырткан —
Йөзмиме соң мондый савыт?!
Чуклар таккан әбекәйнең
Шәленнән чук кисеп алып.

Гаҗәп әйбәт көймәләре!
Үсә минем әнем, үсә.
Артыграк тырышканмы —
Өйдә каеш җиле исә...

ҖИЛӘКЛЕ АЛАН

Менә шушы юл бит инде
Урманга алып бара.
Йөгертеп кенә йөртә ул,
Гел якынная ара.
Бер менәсең нәни тауга,
Бер тәгәрәп төшәсең,
Җиләккә барып җиткәнче
Җиләк кебек пешәсең.

Юлның ике кырыенда
Ат арбасы эзләре.
Шул эзләргә тулган сулар
Гүя юлның күзләре.

Шул күзләрдә әле кояш,
Әле болыт күренә.
Җилләр кагылып уза да
Әбием битендәгедәй
Җыерчыклар йөгерә.

Юл буйлары чирәм генә,
Тәгәрәп уйнап алам.
Җилме, минме иркәләгән
Кул болгап калды балан.

Әле моннан шактый ерак
Җиләкле аланыма,
Аланымны белсә белә
Бары шул балан гына.

Ул да белми, каян белсен,
Мин әйтәмме соң инде.
Әбием мең кат сандыкта
Сакла ди бит серенне.

Әбинең өйдә сандыгы
Әле бер катлы гына.
Ан-да-гы сер! Тик шунсы бар:
Ул да йозаклы гына.

Урман әби сандыгыннан
Бик күпкә серлерәктер.
Йозагы юк, ләкин серне
Саклау хәерлерәктер.

Урманга җиттем. Имәннәр
Чикләвек үстергәнме?
Шомыртка, кыргый алмага
Әле тәмнәр кергәнме?

Тиен дустым йөгереп төшеп
Кулдан ризык алырмы?
Кайткан чакта юлга кадәр
Мине озата барырмы?

Барлыйм тырысыма салган
Ипиемне, сөтемне,
Чикләвекне, кишерне —
Дуслар көтә бит инде.

Күпме гөлләр көтә мине,
Көтә таныш куяным.
Тиенем көтә, ул инде
Күптән чыккан уянып.

Саумы, алан! Кочагыңа
Мәтәлчек атып керәм,
Мине уч төбендә тотып
Тирбәтеп тора үлән.

Ә чәчәкләр мине күргәч
Нәрсәдер сөйләшәләр.
Саумы, абый, килдеңме дип
Мөлаем эндәшәләр.

Нихәл, исәнме, керпе дус,
Сине онытаммы соң,
Сыерыбыз сөтле безнең,
Сине ач тотаммы соң!

Яле савытыңа салыйк,
Сөтебез шундый тәмле,
Вак-вак итеп ипи турыйк —
Туклыклы булсын, яме?

Куян дус! Әйдә, рәхим ит
Безнең белән табынга,
Менә кишер ашап җибәр,
Ял итик бераз гына.

Тиен дус! Чикләвекләрнең
Иң сарылары сиңа,
Агач башыннан төш әле,
Утыр бер минут кына.

Кабат кибәргә әләрсең,
Куеп тор гөмбәләрне,
Дуслар җыелган табынга
Ямь өстәп җибәр әле.

Дусларымны күргән саен
Бер уй ныгый күңелдә:
Барыбыз бертуган булып
Яшисе иде җирдә.

Өйгә кайткач әти белән
Киңәшеп алыйк әле,
Риза булса яңа өйне
Шушында салыйк әле.

Тиен белән рәхәтләнеп
Чикләвек җыяр идек,

Гөмбәләр тозлар идек,
Кибәргә куяр идек.

Керпе белән бакчабызда
Алмалар кояр идек,
Сыер күбрәк сөт бирсен дип
Печәннәр җыяр идек.

Бал кортлары бал ташырлар
Барыбызны сыйларга.
Аннан бик шәп булыр иде
Бергәләшеп уйнарга.

Аланым мине бер тырыс
Җиләк биреп озата,
Җиләге белән өемә
Матур уйларым кайта.

НИК ҮЗГӘРДЕМ?

Кайчагында энем кебек
Елак-мылак булса да,
Баскыч төбендә калдырган
Ботинкама тулса да,
Иртә белән яуса да,
Йоклап соңга калса да,
Яңгыр, яңгыр, яу! — диеп
Кычкырдым мин сөенеп.
Мин кечкенә чагымда
Дус идем шул яңгырга.
Печәннәр һәм игеннәр
Теземгә салынганда,
Басуда шау-гөр килеп
Бәрәңге казыганда,
Әтиләр өмә белән
Өй күтәргән чагында,
Асфальт юл түшәгәндә
Төзүчеләр авылда,
Ындыр табакларында
Икмәкне җилгәргәндә,
Абыемны солдатка
Озатып җибәргәндә
Яңгыр арага керсә,
Эшкә аяк чалып йөрсә,
Мин яңгырга үпкәлим,
Ачуланам, шелтәлим.
Ник үзгәрдем икән? — дим.
Әти әйтә: Үстең син,
Ил йөге, ди, җилкәңдә.
Карыйм: иңдә берни юк,
Ник алай ди икән, ә?

МИНЕМ СУМКА

Әти сумка алды миңа
Шундый матур, өр-яңа,
Өйдәге дус курчагым да
Сокланып карый аңа.
Әлифба һәм дәфтәрләрем
Яши хәзер сумкада.
Көн буе күтәреп йөрим,
Сумкам авыр булса да.
Ак алъяпкычымны кидем,
Сентябрь килеп җитте,
Курчагыма: — Сау бул,— дидем,—
Апаң мәктәпкә китте.
Минем сумканы яфраклар
Күрергә үреләләр,
Шулкадәр иеләләр,
Ботактан өзеләләр.
Мин узып йөргән урамда
Шәрә калды бар агач.
Көзне орыша күрмәгез,
Нихәлләр итим соң инде
Бүтән сумкам булмагач.

ЭНЕМ

Энем әле бүген генә
Кулына чалгы алды.
Аякларын аерып басып
Әти кебек кыйланды.

Әй тырыша, бер селтәүдә
Бер кочак печән чыгар,
Бу кадәр печән төясә,
Сәнәкләр ничек чыдар?

Тик менә чабылган үлән
Яңадан торып баса,
Энем аптырамас иде
Кеше карап тормаса.

Маңгаеннан тәгәриләр
Борчак-борчак тирләре.
Әйтте: — Чабырга кызганам,
Бигрәк матур гөлләре!..

Ә ХӘЗЕР

Урамда җил куып йөреп
Күпме тиргеш ашадым.
Ә хәзер җил мине куа —
Шәп машина ясадым.

Элек тиргеш кенә алсам,
Хәзер бүләкләр алам,
Ярышларда малайларны
Артта калдырып чабам.

Нинди машина ул диеп,
Дускай, теңкәгә тимә,
Җилдән җитез машинабыз
Була җилкәнле көймә.

ҖӘЙГЕ КӨН

Кояш битне яндыра,
Күзләремне талдыра.
Маэмай да чапмый бүген,
Менә шундый эссе көн.

Сыерларны куып та
Чыгарып булмый судан,
Абыем да күләгәгә
Атын тугарып куйган.

Үзе тәрәзәдән карап
Чәй эчә дә чәй эчә,
Нәрсә була бахбаена
Шикәр белән чәй бирсә.

Түз, бахбай, сабыр иткән бит
Морадына, ди, җиткән.
Көт, мин сиңа мороженый
Алып киләм кибеттән.



ЧЫПЧЫКЛАР

Һәр көн тимер чыбыкларга
Чыпчыклар тезеләләр,
Әллә бәхәсләшә алар,
Әллә миннән көләләр.

Энем кебек чытлык алар,
Һич урында тормыйлар,
Әллә безнең телефоннан
Сөйләшкәнне тыңлыйлар.

Энем таш җыя, кошларга
Дошманлык бар уенда.
Ә мин уйлыйм:
Тимер чыбык, дим, Гөлназга —
Тере чыпчыклар тезелгән
Гаҗәеп шәп муенса...

БЕЗ ЯРМИНКӘ ҮТКӘРДЕК

Әле сез белмисездер,
Әгәр күргәнсез икән
Сагынып сөйлисездер.
Тынычлык файдасына
Без ярминкә үткәрдек.
Шәп булды, искитәрлек.
Җыелышып сөйләштек,
Бәхәсләштек, киңәштек.
Алсу чәк-чәк пешерде,
Телне йотарлык инде.
Кызлар чикте ашъяулык,
Кулъяулык һәм башъяулык.
Илһам ясаган көрәк
Һәр хуҗалыкка кирәк.
Фәнис ясаган тырыс,
Алып калырга тырыш.
Ә мин атна буена
Сыбызгылар ясадым,
Ярминкәне ачуга
Кызып сата башладым.
Күзне ачып йомганчы
Өстәлем бушап калды,
Ә соңгы сыбызгыны
Директор абый алды!
Шундый каты сызгыртты,
Мәктәптә сызгыртырга
Ярамый бит, онытты.
Сыбызгысы әйбәт шул,
Шуңа оныттыра ул.

ЫК-МЫК

Шулай беркөн урамда
Бәхәсләшеп торганда,
Көтү куган урында
Йөгерешү турында
Фаил шундый шартлатты,
Барыбыз да шаккатты.
Кичә шундый чаптым, ди,
Башта уздым атны, ди,
Аннан уздым ЗИЛне, ди,
Иң соңыннан җилне, ди.
Булды, ышандык, дидек,
Чынга охшарлык, дидек.
Атны, ЗИЛне күргән бар,
Утырып та йөргән бар.
Авырга алма инде,
Алып кил монда җилне.
Фаил дус ык-мык итте
Һәм... җилне эзләп китте...

САНДАЛЫМ

Сандыкта җәйне сагына
Өр-өр-яңа сандалым,
Кыш килде шул, аны киеп
Беркая да бармадым.
Телевизордан җәй аен
Күрсәткән көнне генә
Сандалымны киеп алып
Йөрим өй идәнендә.
Әни кулы сыман йомшак,
Бигрәк шәп сандал икән.
Рәхәтләнеп кию өчен
Кошлар белән җылы якка
Китәсе калган икән.



КЫНА ГӨЛЛӘР

Гөлназлар тәрәзәсеннән
Кыналар көлеп тора,
Күзем гел шул тәрәзәдә —
Алар шул белеп тора.
    Кайчагында ул кыналар
    Селкенгән кебек була,
    Әллә Гөлназның күлмәге,
    Әллә тәрәзә пәрдәсе
    Җилкенгән кебек була.
Ул чагында мин болытка,
Шомыртка карап торам,
Күлмәгемнең якаларын
Төзәткән кебек булам.
    Әллә гөлләр белеп тора,
    Шуңамы көлеп тора?
    Яңа чалбарны үтүкләп
    Кигәнне күреп тора.
Чәчләрем дә төзәтелгән
Бабай пәкесе тигәч,
Нихәл итим соң, кыналар,
Сезне күрәсе килгәч.

КУРЫКМЫЙБЫЗ

Безнең семья кемнән ким? —
Бабай, әти, абый, мин.
Әби, әни, апалар,
Энем белән сеңлем бар.
    Кич утырып сөйләштек,
    Исәпләдек, киңәштек.
Исәп: быел җәй көне
Ныклап сызганып җиңне
Үстерәбез бергәләп
Без азык чөгендере.
Абый эшкәрткән басу
Өстәл кебек тип-тигез.
Амбардан орлык ташыдык
Әти белән икебез.
Абый ашлама сала,
Әти белән мин — орлык.
Бабай әйтә: — Язгы көннәр,
Улым, ел туйдырырлык.
Җиргә йомыркалар чәчә
Бабай изге гадәт дип,
Энемнең күзе елтырый,
Менә монсы әйбәт, дип.
Трактор китте кузгалып,
Чәчкеч челтерәп бара.
Орлык белән безнең җиргә
Тургай җырларын яза.
Су сиптерергә дә кирәк,
Чүпләрне утыйсы бар.
Мул уңыш серен ачучы
Китаплар укыйсы бар.
Чөгендер теге шалканнан
Зур үссен, курыкмыйбыз.
Көч җитмәсә, техника бар,
Бергәләшеп йолкыйбыз!

ЭЧТӘЛЕК

Җиләккә барган идек	3
Безнең урам	7
Көнне үзем җылытам	8
Күршебезгә бер кыз килгән	10
Һич тә уйламаганда	11
Ял көнендә	12
Саескан кунса...	13
Хәлне әни күрәсе бар	13
Кем ул?	14
Безнең өйдә ике әтәч	15
Инеш	16
Ике көннең берендә	17
Энем үсә	18
Җиләкле алан	19
Ник үзгәрдем?	23
Минем сумка	24
Энем	25
Ә хәзер	25
Җәйге көн	26
Чыпчыклар	27
Без ярминкә үткәрдек	28
Ык-мык	29
Сандалым	29
Кына гөлләр	30
Курыкмыйбыз	31

Газизов Рафаиль Шакурович

ЯГОДНАЯ ПОЛЯНА

Стихи

(на татарском языке)

ИБ № 4922

Редакторы Т. Нурмөхәммәтов. Художество редакторы Ф. Хәсьянова. Техник редакторы Э. Трофимова. Корректоры Р. Хәмидуллина. Җыярга тапшырылды 2.03.88. Басарга кул куелды 14.06.88. Форматы 60×90[1]/16. Типогр. кәгазе № 1. Школьная гарнитурасы. Кабарынкы басма. Басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 2,5. Нәшер-хисап табагы 1,52. Тиражы 10 000 экз. Заказ Е-150. Бәясе 10 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

10 тиен.